**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе**
**“В.Ф.Тарасов исемендәге Иске Мукшы урта гомуми белем бирү мәктәбе”**

| **«Раслыйм»** | **«Килешенде»** | **«Килешенде»** |
|---|---|---|
| Директор:<br>__________Шәрәфетдинов Р.Г.<br><br>Боерык №<br>«__28__» август 2014 нче ел. | Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары:<br>_____________Козлова Н.В.<br><br>«__28__» август 2014 нче ел. | Методик берләшмә җитәкчесе<br>__________Шәрәфетдинова Г.Ф<br><br>Беркетмә № __1_<br>«_25___» август 2014 ел. |

**7 нче “А” сыйныфы өчен татар теленнән эш программасы**
**(татар төркеме)**
Төзүче: югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Шәрәфетдинова Гүзәл Фәсхетдин кызы

Педогогик киңәшмә
утырышында каралды.
Боерык № 1

2014-2015 нче уку елы

## Татар теленнән эш программасы

## 7 нче сыйныф (татар төркеме)

## (105сәг)

### Аңлатма язуы

**Эш программасы статусы**.

<u>Әлеге эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелгән:</u>

1 . “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең Законы

2. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законы

3. “2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы” (№794 от 25.10.2013)

4. Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты.-ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан , 2008

5.“Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары” на (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Р.Ф.Җамалетдинова. 1- 11 нче сыйныфлар. - Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2010),

6.. 2014/2015 нче уку елында татар телен укыту үзенчәлекләре.(Методик тәкъдимнәр)

7..Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының МБГБУ“В.Ф.Тарасов исемендәге Иске Мукшы урта гомуми белем бирү мәктәбе” нең уку планы (Уку планы буенча боерык №179 1нче сентябрь 2014 нче ел)

8. Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәбенең. 7 нче сыйныфы өчен дәреслек (татар балалары өчен)/

**Эш программасы структурасы.** Татар теленнән эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.

**Эш программасының эчтәлеге**.

Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, «укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш”. Бу – яңа стандартта эшлекле белем дип атала. Эшлекле белем – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата:

Татар теле укытуның максатлары:

Укучыларда татар теленә хөрмәт һәм аны ярату, рухи кыйммәт һәм кешелек дөньясының аралашу, белем алу чарасы буларак аңлы караш тәрбияләү;

Укучыларның сөйләү һәм фикерләү сәләтен үстерү, аларны татар әдәби телен тормышның төрле өлкәләрендә иркекле куллана алырлык шәхесләр итеп тәрбияләү; дөрес сөйләм эшчәнлегенең үзара аралашу чарасы икәнен белдерү;

Татар теле, аның төзелеше, кулланылышы турында мәгълүмат алу; татар әдәби теленең төп нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллау, аларны тиешенчә куллана белү; сүз байлыгын арттыру, сөйләмдә кулланыла торган грамматик чараларны төрлеләндерү;

Телне өйрәнгәндә үзләштергән белем һәм күнекмәләрне сөйләмдә дөрес куллана белү.

## Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы.

**Коммуникатив компетенция.** Сөйләм. Телдән һәм язма сөйләм. Диалогик һәм монологик сөйләм. Сөйләм стильләре. Матур әдәбият теле.

Телдән һәм язма сөйләмне аеру. Тел берәмлекләрен аралашуны ситуация үзенчәлекләренә карап сайлый белү. Аралашу өлкәсенә һәм ситуациясенә бәйле рәвештә телдән һәм язма сөйләмне дөрес файдалану.

Текстның темасы, төп фикере һәм төзелеше. Аларның стильләрендә жанр төрлелеге.

Татар әдәби теле һәм аның нормалары турында төшенчә.

Сөйләм эшчәнлеге төрләрен (тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм язу) үзләштерү.

Укуның төрле төрләрен (танышу, өйрәнү һ.б.)үзләштерү. Уку киталары, масса күләм мәгълүмат чаралары, интернет һ.б. чаралар белән эшләү алымнарын үзләштерү.

Иҗтимагый-мәдәнии, әхлакый, көнкүреш, уку темаларына бәйле булган монологтк һәм диалогик сөйләм үрнәкләрен төзү.

Текстның эчтәлеген кыскача , тулы яки сайлап алып сөйләү. Диктантлар, изложениеләр һәм сочинениеләр язу. Төрле стилҗ һәм жанрдагы текстлар төзү: бәяләмә, аннотация, хат, ышаныч кәгазе, гариза, тезис, конспект һ.б.ш.

**Лингвистик компетенция.** Телнең кеше тормышында һәм җәмгыятьтә тоткан урыны. Татар теле – Татарстан Республикасының дәүләт теле. Татар теле – татар халкының милли теле.

Матур әдәбият һәм аның нормалары турында төшенчә.

Татар теленең үсештә булуы. Соңгы елларда татар теле лексикасындагы үзгәрешләр.

Тел белеменә караган сүзлекләр һәм алардан файдалану.

Укыту планында 7 нче сыйныфта татар теленнән атнага 3 сәгать вакыт бирелә. Татар теленнән тематик планны “Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары”на (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Р.Ф.Җамалетдинова. Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2010) нигезләнеп төзедем. Программада 105 сәгать каралган: теоретик материал –61 сәгать, кабатлау -13 сәгать, бәйләнешле сөйләм үстерү – 28 сәгать, төрле типтагы тикшерү эшләре - 19 сәгать.

| № | Төп темалар | Сәг. | Белем һәм күнекмәләр |
|---|---|---|---|
| 1 | 6 сыйныфта үткәннәрне кабатлау. | 7 | - морфология турында төшенчә, исем, сыйфат, сан, алмашлык; |
| 2 | Фигыль | 7 | фигыльнең башлангыч формасы, фигыльләрнең барлык-юклык формасы, фигыль юнәлешләре, фигыль төркемчәләре; |
| 3 | Затланышлы фигыльләр | 15 | боерык фигыль, боерык фигыльнең зат-сан белән төрләнеше, боерык фигыльләрнең дөрес интонация һәм басым белән кулланылышы,;<br>хикәя фигыль, хәзерге заман хикәя фигыль, хәзерге заман хикәя фигыльнең мәгънәләре, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | үткән заман хикәя фигыль, үткән заман хикәя фигыльнең мәгънәләре, билгесез үткән заман хикәя фигыль, киләчәк заман хикәя фигыль, билгесез киләчәк заман хикәя фигыль, киләчәк заман хикәя фигыльнең мәгънәләре;<br>шарт фигыль, шарт фигыльнең җөмләдә кулланылышы, шарт фигыльнең теләкне һәм үтенүне белдерү формалары; |
| 4 | Затланышсыз фигыльләр. | 18 | сыйфат фигыль, сыйфат фигыльнең сыйфат һәм фигыль белән уртак яклары, үткән заман сыйфат фигыль, киләчәк үткән заман сыйфат фигыль;<br>хәл фигыль, хәл фигыльнең төрләре, хәл фигыльнең фигыльнең җөмләдә кулланылышы һәм дөрес язылышы;<br>исем фигыль, исем фигыльнең исем һәм фигыль белән уртак яклары, исем фигыльнең исемгә әйләнү очраклары;<br>инфинитив;<br>ярдәмче фигыльләр, мөстәкыйль фигыльләрнең ярдәмче фигыль ролендә йөрүе, фигыль ясагыч кушымчалар; |
| 5 | Аваз ияртемнәре | 4 | аваз ияртемнәре, аваз ияртемнәренең сүзләр ясауга нигез булып торулары, аваз ияртемнәренең җөмләдә кулланылышы; |
| 6 | Хәбәрлек сүзләр | 4 | хәбәрлек сүзләр, хәбәрлек сүзләргә морфологик анализ; |
| 7 | Ярдәмлек сүз төркемнәре:<br>Бәйлекләр<br>Теркәгечләр<br>Кисәкчәләр<br>ымлыклар | 16<br>5<br>5<br>4<br>2 | бәйлек, бәйлекләрнең төркемчәләре, бәйлек сүзләр, бәйлекләргә морфологик анализ;<br>тергәгеч, тезүче теркәгечләр, ияртүче теркәгечләр, теркәгеч сүзләр;<br>кисәкчәләр, кисәкчә төркемчәләре, кисәкчәләрнең дөрес язылышы;<br>ымлыклар, ымлыклар янында тыныш билгеләре; |
| 8 | Кабатлаулар | 13 | |
| 9 | Бәйләнешле сөйләм үстерү | 28 | |

***Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:***

- ана теленең төп берәмлекләрен һәм аларның билгеләрен белү;
- телдән һәм язма сыйләм, диалог, монолог, аралашу ситуацияләрендә тел стильләре, текст төшенчәләрен аңлау һәм гамәлдә дөрес куллану;
- тыңлап аңлау һәм уку буенча телдән һәм язма рәвештә (радио, телевеведениедән һ.б.) хәбәр ителгән мәгълүматны аңлау;

сөйләү һәм язуда татар әдәби теленең төп нормаларын (орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик һәм пунктацион)саклау һәм сөйләм әхлагы нормаларын үтәү;

- татар теленең фонетик, лексик системаларын һәм грамматик төзелешен үзләштерү;
- сүзләрне төзелеше һәм ясалышыбуенча тикшерә белү;
- текст төзелешен һәм тел үзенчәлекләрен билгәли белү;
- сөйләм стиле, фәнни, публицистик, рәсми-эш, матур әдәбият стильләрен аерырга өйрәтү;
- ана теленеү грамматик категорияләрен белү;
- грамматик үзенчәлекләренә карап, сүз төркемнәрен аера белү;
- сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау;
- сүз, сүзтезмә, җөмләләрдәге хаталарны төзәтү;

- җөмләгә синтаксик анализ ясау;
- төрле стиль һәм жанрдагы текстларны тиешенчә уку күнекмәләре булдыру;
- төрле сүзлекләрдән һәм белешмә характерындагы китаплардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан урынлы файдалану;
- синтетик һәм аналитик иярченле кушма җөмләләрне сөйләмдә куллана белү;
- текстның эчтәлеген телдән яки язмача төгәл итеп, сайлап яки кыскача, гади һәм кушма җөмләләр кулланып сөйли белү;
- бирелгән темага, куелган максатка ярашлы рәвештә, төрле ситуацияләрдән чыгып, сурәтләү яки хикәяләү характерындагы текстларны телдән яки язмача әзерләү;
- җөмләнең тиңдәш кисәкләрен, аерымланган кисәкләрен тиешенчә куллана белү, алар янында тыныш билгеләрен кую;
- сорауларга тулы һәм дөрес итеп җавап бирү;
- тормыш-көнкүреш, уку, иҗтимагый, мәдәни темаларга әңгәмә кору, үз фикереңне яклап, әңгәмә-бәхәс формасында сөйләшү күнекмәләренә ия булу"
- туры һәм кыек сөйләмнән урынлы файдалану, алар янына тиешле тыныш билгеләрен кую;
- текстның планын төзү яки аның эчтәлеген конспект формасында язу;
- тәкъдим ителгән текстларны рку теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү;
- ана теленең башка фәннәрне өйрәнү һәм белем алу чарасы икәнен аңлау;
- татар теле дәресләрендә алган белем һәм күнекмәләрне ана теленең кеше һәм җәмгыять тормышында алып торган урынын аңлап куллана һәм бәяли белергә өйрәнү, татар теленең Татарстан Республиуасында дәүләт теле буларак өйрәнелүен, аның иҗтимагый әһәмиятенең артуын аңлау

***VII нче сыйныфта татар теленнән үзләштерелергә һәм камилләштерелергә тиешле гомумкүнекмәләр***

| Уку эшчәнлеген оештыра белү юнәлешендә | Китап, өстәмә мәгълүмат белән эш итү | Фикерләү белән бәйле күнекмәләр | Телдән һәм язма сөйләм үстерү һәм аралаша белү юнәлеше |
|---|---|---|---|
| 1. Уку мәсьәләләрен мөстәкыйль билгеләү<br>2. Уку операцияләрен планлаштыру.<br>3. Белем алуның рациональ ысулларын сайлау.<br>4Үзеңнең уку һәм танып-белү эшчәнлегеңне анализлау, аңа бәя бирү.<br>5.Мөстәкыйль белем алу буенча эшне планлаштырырга өйрәнү. | 1. Дәреслек белән эш итә белү.<br>2. Төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эш итә белү<br>3. Төрле текстлардан төп фикерне аерып ала белү, текстның ло- гик схемасын билгеләү, гади һәм катлаулы план белән эш итү.<br>4. Белемнәрне системалаштыру өчен таблица, график, схемалардан файдалану. .<br>5. Эчтәлекне аңлап, тиешле тизлектә, дөрес уку:<br>-уку елы башында-80-95 сүз | 1.Уку мәсьәләсен куя белү.<br>2. Яңа теманы аңлауга мотив тудыру.<br>3. Танып белү активлыгын үстерү.<br>4, Төшенчә, термин, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү күнекмәләрен камилләштерү.<br>5. Грамматик анализ төрләрен үзләштерү:<br>- мөстәкыйль сүз төркемнәренә морфологик анализ;<br>- ярдәмлек сүз төркемнәренә морфологик анализ;<br>6. Тикшерену ысуллары: | 1. Телдән сөйләм:<br>-Кагыйдәләрне аңлап эзлекле сөйли белү күнекмәсе;<br>- Сорауны формалаштыра белү һәм тулы җавап бирә белү күнекмәсе;<br>- Диалоглар төзү күнекмәсе;<br>- Үрнәк схема планнар ярдәмендә характеристика төзи белү күнекмә -се.<br>2. Язма сөйләм:<br>-күчереп язу;<br>-фикер йөртү элементлары кертеп, әзер план буенча бирелгән темага сочинение язу- 6 (1) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | -уку елы ахырында-85-100 сүз<br>6. Сүзлекләрдән файдалана белү, белешмә әдәбият белән система- лы эшләү.<br>7. Вакытлы матбугат басмалары белән даими эшли белү | - модельләштерү;<br>-охшатып эшләү.<br>7. Логик алымнардан чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау күнекмәләре булдыру. | -катлаулы план буенча изложение язу- 5 (2)<br>уку елы башында 190-230 сүзле текст (язма күләме 105-115 сүз) уку елы ахырында 270-280 сүзле текст (язма күләме115-125 сүз);<br>-сүзлек диктанты – 122-30 сүз<br>-контроль диктант- 2 (65-80 сүз);<br>-эш кәгазьләре язу ( гариза, хат, акт) |

***Тематик план***

| Барлыгы | Теоретик материал | Кабатлау | Бәйләнешле сөйләм үстерү | Шулардан: диктанат | Сочинение | Изложение |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 105 | 61 | 13 | 28 | 7 (2) | 7 (2) | 5 (2) |

| № | Дәрес темасы | Сәгать саны | Дәрес тибы | Дәрестә кулланылга эш төрләре | Контроль төре | Үзләштерергә яки камилләштерергә тиешле белем һәм күнекмәләр | Өй эше | Дата | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | План | Факт |
| 1 | Бсү. Туган тел турында әңгәмә. | 1 | Бсү | Әңгәмә | Терәк сүзләр буенча хикәя төзү | “Туган телем – иркә гөлем Киңдер сиңа күңел түрем” темасына сөйләшү. | Хикәя “Туган телем – иркә гөлем Киңдер сиңа күңел түрем”. | 02.09 | |
| 2 | Морфология турында төшенчә | 1 | Кабатлау дәресе | | Сүзлек диктанты (ялгызлык, уртаклык исемнәре) | Мәгънәләре һәм грамматик билгеләре буенча бер төркемгә берләштерелә торган сүзләрне *сүз төремнәре* дип атау. Телдә барлыгы 12 сүз төркеме булу. Аларның мөстәкыйль (исем, сыйфат,сан, алмашлык, рәвеш, фигыль, аваз иятремнәре), бәйләгеч (бәйлек, теркәгеч), модаль (хәбәрлек сүз, ымлык, кисәкчә) сүз төркемнәренә бүленү. | 7 нче күнегү, бирем буенча.<br>2.8 нче күнегү, бирем буенча | 03.09 | |
| 3 | Исем | 1 | Кабатлау | | Хәтер | Ялгызлык, уртаклык исемнәр. | 18 нче күнегү, | 05.09 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | дәресе | | диктанты. 17 нче күнегү. | Исемнәрнең берлек-күплек саны, килеш һәм тартым белән төрләнеше. Исемнәрнең ясалышы. | бирем буенча. 2.17 нче күнегү, бирем буенча. | | |
| 4 | Сыйфат | 1 | Кабатлау дәресе | | Ышаныч кәгазе язу. | Сыйфат. Сыйфат дәрәҗәләре. Сыйфатларның ясалышы һәм язылышы. Сыйфат ясагыч кушымчалар. Гариза язу. | 1.40 нчы күнегү, бирем буенча. 2. 39 нче күнегү, шигырьне ятларга. | 9.09 | |
| 5 | Сан . Бсү. Ышаныч кәгазе язу. | 1 | Кабатлау дәресе Сөйләм үстерү | | Автобиография язу. | Сан сүз төркеме. сан төркемчәләре. Ышаныч кәгазе язу. | 47 нче күнегү, саннарның төр - кемчәләрен бил геләргә.2.сан кергән 5 мәкаль өйрәнеп килергә | 10.09 | |
| 6 | Алмашлык. Бсү. Автобиография язу. | 1 | Белемнәрне ныгыту дәресе Сөйләм үстерү | | Тест куллану | Алмашлык. Алмашлык төркемчәләре. Автобиография язу. | 61 нче күнегү, бирем буенча. | 12.09 | |
| 7 | Рәвеш | 1 | Мөстәкыйль эш дәресе | | “Дару үләннәре”, 79 нчы бит. | Рәвеш. Рәвеш төркемчәләре. Рәвешләрнең ясалышы, дөрес язылышы. | 74 нче күнегү, бирем буенча. | 16.09 | |
| 8 | Сайланма диктант .”Әбекәй” | 1 | Кабатлау дәресе | | Диктант “Әбекәй” | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү. | Ясалма рәвешләр | 17.09 | |
| | | 1 | **Ф И Г Ы Л Ь** | | | | | | |
| 9 | Фигыль | 1 | Яңа материал белән таныштыру дәресе | | | Предмет яки затның эшен, хәрәкәтен, хәл -торышын белдерә торган белдерә торган сүзләрнең фигыль дип аталуы. Эшне белдерүче фигыльләрнең нәрсә дә булса эшләү, сөйләү, фикерләү мәгънәсен белде- рүләре. Хәрәкәтне белдерүче фигыльләреņ нәрсәнең дә булса хәрәкәтен; хәл-торыш фигыльләре яшәү-торышны, хисне белдерүләре. Фигыл-ләрнең *нишли? нишләде? нишләгән? нишләр? нишләячәк?* | 77 нче күнегү, бирем буенча. 2.76 нче күнегү, бирем буенча. | 19.09 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | кебек сорауларга җавап бирүләре, җөмләдә күбрәк хәбәр булып килүләре. Фи- гыльләрнең барлык-юклык, заман, зат-сан белән төрләнү, төрләнмәүләре. | | | |
| 10 | Фигыльнең башлангыч формасы | 1 | Яңа материал белән таныштыру дәресе | | | Фигыльнең төп мәгънәсе аның тамырында яки нигезендә булу. Тамыр яки ясалма нигезле фигыльләр булу. Тамыр нигезле фигыльдә кушымчалар булмау, ә ясалма нигезле фигыльдә ясагыч кушымчаларның булуы. Сүзлекләрдә фигыльнең исем фигыль һәм инфинитив формасында теркәлүе. Татар 1телендә тезмә нигезле фигыл ләрнең дә булуы, аларның исемгә яки аваз ияртемнәренә ярдәмче фигыль өстәлеп ясалулары (карар кылу, ярдәм итү ). | 81 нче күнегү, бирем буенча. 2.Күнегүдә бирел -гән фигыльләр -не кулланып, 5-6, мәгънә ягыннан бәйләнешле, җөм -лә төзеп язарга. | 24.09 | |
| 11 | Фигыльләрнең барлык-юк лык формасы | 1 | Катнаш дәрес | | | Фигыльләрнең барлык-юклык формасында килүе. Барлык төре эш-хәлнең үтәлүен белдерүе, юклык төре эш-хәлнең үтәлмәвен белдерүе. Юклык формасындагы фигыльләрдә басым юклык кушымчасы алдындагы иҗеккә төшүе. Юклык формасының тамыр яки ясалма нигезгә *–ма/-мә, -мый/-ми* кушымчалары ялганып ясалуы. Фигыльләрнең барлык-юклык төре *бар, юк, түгел* сүзләре белән дә белдерелүе. | 85 нче күнегү, бирем буенча. | 26.09 | |
| 12 | Сочинение.”Яраткан укытучым” | 1 | Бсү | | | Сочинение фикерләү. | Дәфтәрләргә язып килергә | 27.09 | |
| 13 | Фигыль юнәлешләре | 1 | Яңа материал белән таныштыру дәресе | | | Фигыль юнәлешләре эш белән эш үтәүче арасындагы төрле мөнәсәбәтләрне белдерә. Татар телендә фигыльнең биш юнәле-ше булу: *төп юнәлеш, кайтым юнәлеше, төшем юнәлеше,* | 87 нче күнегү, бирем буенча | 01.10 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | *уртаклык юнәлеше, йөкләтү юнәлеше.*<br>-Төп юнәлештә үтәүче эшне үзе башкара, кушымчасы юк:<br>-кайтым юнәлешендә эш үтәүченең үзенә кайта, кушымчалары: -н, -ын, -ен.<br>-төшем юнәлешендә эш кешегә яки предметка читтән төшә, кушымчалары: -л, -ыл, -ел.<br>-уртаклык юнәлешендә үтәүче эшне кем беләндер бергә эшлә, кушымчалары: -ш, -ыш, -еш.<br>-йөкләтү юнәлешендә үтәүче эшне кемгәдер йөкләтеп эшләтә яки эшнең үтәлүенә сәбәпче була, кушымчалары: -дыр, -дер, -тыр, -тер, -т. | | | |
| 14 | Бсү. Тәрҗемә итү | 1 | Бсү | | Тәрҗемә итү | Тәрҗемә иткәндә татар һәм рус телләренең җөмлә төзелешенә игътибар итү. | Индивидуаль бирем | 03.10 | |
| 15-16 | Фигыль юнәлешләре | 2 | Катнаш дәрес Белемнәрне ныгыту дәресе | | Тест куллану | Фигыль юнәлешләрен истә калдыру буенча күнегүләр эшләү. Һәрбер фигыльне биш юнәлешкә дә куеп булмау. Рус телендә фигыльләрнең төп өч юнәлеш булуы: *действитель- ный залог* (төп юнәлеш), *страдательный залог* (төшем юнәлеше), *возвратно-средний залог* (кайтым юнәлеше). Уртаклык юнәлешенең *взаим ный залог,* йөкләтү юнәлеше *побудительный залог* дип тәрҗемә ителүе. | 1.90 нчы күнегү, бирем буенча.<br>2.Бер фигыльне белән җөмләләр төзегез.<br>“Ялкын” журна-лыннан яки үзегез укый торган китаптан төрле юнәлешләрдәге фигыльләрне җөмләләре белән күчереп языгыз, юнәлешлшрен билгеләгез. 5 җөм | 04.10<br>08.10 | |
| 17 | Фигыль төркемчәләре | 1 | Яңа материал белән таныштыру дәресе | | Сүзлек диктанты (7 мин) | Фигыльләрнең предметның яки затның эшен төрлечә белдерү - ләре. Аларның төрләнешенә, җөмләдә башкарган эшенә карап, җиде төркемчәгә бүлү: боерык | 96 нчы күнегү, бирем буенча | 10.10 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | фигыль, хикәя фигыль, шарт фигыль, сыйфат фигыль , хәл фигыль, исем фигыль, инфинитив. Барлык төркемчә -ләргә кергән фигыльләр барлык -та-юклыкта килә алалар, төрле юнәлеш формалары алалар. | | | |
| | | | **ЗАТЛАНЫШЛЫ ФИГЫЛЬЛӘР** | | | | | | |
| 18 | Боерык фигыль | 1 | Яңа материал белән таныштыру дәресе | | | Боерык фигыльнең эш кушуны, боеруны белдерүе., зат-сан белән төрләнүе, барлыкта яки юклыкта килүе, җөмләдә хәбәр булуы. | 99 нчы күнегү, бирем буенча | 11.10 | |
| 19 | Боерык фигыльнең зат-ман белән төрләнеше | 1 | Катнаш дәрес | | | Боерык фигыльзаман белән төрләнмәве. II зат боерык фигыльнең кушымчасы булмавы. | 100 нче күнегү, бирем буенча, җөмләләр төзегез. | 15.10 | |
| 20 | Боерык фигыльләрнең дөрес интонация һәм басым белән кулланылышы | 1 | Катнаш дәрес | | Тест 7 мин | Боерык фигыльләрнең көчле интонация һәм басым белән әйтелеше. Боерык фигыльдә басымның үзгәрүе: II затның берлек һәм күплек санында беренче, I һәм III затта соңгы иҗеккә төшүе. | 110 нчы күнегү, бирем буенча | 17.10 | |
| 21 | Хат язу | 1 | Бсү | | Хат язу. | Дустыма хат язу яки әбигә,бабайга хат | Авылга-бабайга хат язарга | 18.10 | |
| 22 | Изложение (контроль) “Куян рәхмәте” | 1 | Бсү | | | Бирелгән текстның телен һәм стилен саклап язу. | Өй эше бирелмәде | 22.10 | |
| 23 | Хикәя фигыль | 1 | Яңа материал белән таныштыру дәресе | | | Хикәя фигыльнең эш-хәл, хәрәкәтнең хәзерге, үткән, киләчәк заманда үтәлү-үтәлмәвен хикәяләп белдерүе, барлыкта-юклыкта килүе, зат-сан белән төрләнүе. Хикәя фигыль җөмләдә хәбәр булып *нишли? нишләде? нишләгән? нишләр?нишләячәк?* дигән сорауларга җавап бирүе. | 111 нчы күнегү, бирем буенча. 2. “Ялкын” журна-лыннан 5 җөмлә табып языгыз. (хәзерге -1,үткән, киләчәк -2) | 24.10 | |
| 24 | Хәзерге заман хикәя фигыль | 11 | Катнаш дәрес | | | Хәзерге заман хикәя фигыльнең күбрәк сөйләүче сөйләп торган вакыттагы эш-хәлне, хәрәкәтне белдерүе, нишли? соравына җавап | 114 нчы күнегү, бирем буенча. 2. Шигырьне, яттан диктант итеп | 25.10 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | бирүе, җөмләдә хәбәр булуы. Хәзерге заман хикәя фигыльнең ясалыш ысуллары. Хәзерге заман хикәя фигыль нең зат-сан белән төрләнеше. | әзерләргә. | | |
| 25 | Хәзерге заман хикәя фигыль мәгънәләре | 1 | Катнаш дәрес | | 114 нчы күнегү, яттан диктант. | Хәзерге заман хикәя фигыльнең күбрәк сөйләүче сөйләп торган вакыттагы эш-хәлне, хәрәкәтне белдерүе, *нишли?* соравына җавап бирүе, җөмләдә хәбәр булуы; даими яки гадәт буларак кабатлана торган эш-хәлне, хәрәкәтне белдерүе, якын киләчәктә булуы ышанычлы эшне аңлатуы, сөйләмне җанландыру өчен, үткән заман мәгънәсендә кулланылуы. | 117 нчы күнегү, бирем буенча. | 29.10 | |
| 26 | Диктант .”Чын бәхет” | 1 | | | | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү. | 118 нче күнегү | 31.10 | |
| 27 | Үткән заман хикәя фигыль | 1 | Катнаш дәрес | | | Үткән заман хикәя фигыль сөйләүче сөй- ләп торган вакыттан алда булган эш-хәлне, хәрәкәтне белдерүе. Анық билгеле һәм билгесез үткән заманнарга бүленү. Билгеле үткән заманның *нишләде? нишләмәде?* сорауларына җавап бирүе. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең тамыр яки ясалма нигезгә –ды/-де, -ты/-те кушымчалары ялганып ясалу. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнүе | 120 нчы күнегү, бирем буенча. 2.Сорауларга җавап бирегез. | 01.11 | |
| 28 | Билгесез үткән заман хикәя фигыль | 1 | Катнаш дәрес | | Тест 7 мин. | Сөйләүче үзе катнашмаган, күрмәгәняисә анык белмәгән эш, хәл, хәрәкәттурында бары анық нәтиҗәсе буенча яки башка чыганакларга таянып хәбәр итсә, фигыльнең билгесез үткән заман формасы куллануы. Билгесез үткән заман хикәя фи *–гыльнең* | 123 нчы күнегү, бирем буенча. 2. Шигырьне, яттан диктант итеп әзерләргә | 12.11 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | *нишләгән? нишләмәгән? ни булган?* сорауларына җавап бирүе. Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең ясалышы, зат-сан белән төрләнүе. | | | |
| 29 | Үткән заман хикәя фигыльнең мәгънәләре | 1 | Катнаш дәрес | | 123 нчы күнегү, яттан диктант. | Билгеле һәм билгесез үткән заман хикәя фигыльләрнең мәгънәләрен аера белү | 125 нче күнегү | 14.11 | |
| 30 | Диктант .”Алмаз бабай бакчасы” | 1 | | | | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү. | 127 нче күнегү | 15.11 | |
| 31 | Киләчәк заман хикәя фигыль | 1 | Катнаш дәрес | | | Киләчәк заман хикәя фигыль сөйләүче сөйләп торган вакыттан соң булачак эш, хәлне, хәрәкәтне белдерүе. Аның билгеле һәм билгесез киләчәк заманнарга бүленү. Билгеле киләчәк заманның буласы эш-хәрәкәт турында анык һәм кискен рәвештә хәбәр ителгәндә кулланылуы. Билгеле киләчәк заманның *нишләячәк? нишләмәячәк?* сорауларына җавап бирүе. Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнүе | 128 нче күнегү, бирем буенча. 2.Сорауларга җавап бирегез. | 19.11 | |
| 32 | Билгесез киләчәк заман хикәя фигыль | 1 | Катнаш дәрес | | | Эш, хәл, хәрәкәтнең ктләчәктә булу яки булмавы ихтимал рәвешендә генә хәбәр ителгәндә билгесез киләчәк заман кулла-ныла. Аның *нишләр? нишләмәс?* сорауларына җавап бирүе. Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнүе | 139 нчы күнегү, бирем буенча, 6 җөмлә төзергә. | 21.11 | |
| 33 | Киләчәк заман хикәя фигыльнеңнең мәгънәләре | 1 | Катнаш дәрес | | Тест 7 мин. | Билгеле киләчәк заманның һичшиксез эшләнергә тиешле, эшләнәчәге билгеле булган эш, хәл, хәрәкәтне белдерүе. Билге-сез киләчәк заманның алдагы эш, хәл, хәрәкәтләр турында уйлану, ихтимал итүне белдерү; кискен интонация белән әйте -леп, | 133нче күнегү, бирем буенча. 2. Шигырьне, яттан диктант итеп әзерләргә | 22.11 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | эшләнәчәге ышанычлы бул- ган эш, хәл, хәрәкәтне белдерүе; аерым вакытка карамаган гомуми эш-хәлне белдрүе. | | | |
| 34 | Хикәя язу. “Без хикәя фигыльләр турында ниләр беләбез” темасы буенча | 1 | Бсү | | Хикәя язу | | Дәфтәрләргә язып килергә | 26.11 | |
| 35 | Изложение | 1 | Бсү | | “Менә кем иде ул Алиш”, 56 нчы бит | Бирелгән текстның телен һәм стилен саклап язарга өйрәнү. | Дәфтәрләргә язып килергә | 28.11 | |
| 36 | Шарт фигыль | 1 | Катнаш дәрес | | 133 нче күнегү, яттан диктант. | Шарт фигыльнең икенче бер фигыльдән аңлашылган эш яки хәлнең үтәлү-үтәлмәвенә шарт булган эш-хәлне белдерүе. Шарт фигыльләрнең ясалышы (-са/-сә кушымчасы), зат-сан белән төрләнеше, мәгънәсе. | 139 нчы күнегү, бирем буенча. | 29.11 | |
| 37 | Шарт фигыльнең җөмләдә кулланылышы. | 1 | Катнаш дәрес | | | Шарт фигыльнең икенче бер фигыльгә ияреп килмәгәндә, шартны белдермәве, *теләк, үкенү, үтенү* кебек мәгънәләрне белдерүе. Шарт фигыльнең *да, дә, та, тә* кисәкчәләре белән килеп, *кире шарт* мәгънәсен белдерүе. Шарт фигыльнең иярчен җөмләнең хәбәре булып та килә алуы. | 141нче күнегү, бирем буенча. | 03.12 | |
| 38 | Шарт фигыльнең теләкне һәм үтенүне белдерү формалары. | 1 | Белемнәрне йомгаклау һәм системага салу дәресе | | | *Теләк, үтенү, үкенү* кебек мәгънәләрне белдергәндә *–чы/-че* кисәкчәсе һәм иде ярдәмче фигыле өстәлүе. | 144нче күнегү, бирем буенча. | 05.12 | |
| 39 | Сочинение . МТК “Матур да син, данлы да син, Әй туган ягым” | 1 | Бсү | | Сочинение. | | Дәфтәрләргә язып килергә | 06.12 | |
| | | | **З А Т Л А Н Ы Ш С Ы З Ф И Г Ы Л Ь Л Ә Р.** | | | | | | |
| 40 | Сыйфат фигыль | 1 | Яңа материал белән | | | С-т фигыльнең үзендә *берьюлы сыйфат һәм фигыль билгеләрен* | 152 нче күнегү, бирем буенча. | 10.12 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | таныштыру дәресе | | | берләштерүгә: эш-хәлне предмет -ның билгесе итеп белдерүгә, *нинди? ни эшләүче? нишләгән?* сорауларына җавап биреп, җөмләдә аергыч булып килүгә. | | | |
| 41 | Сыйфат фигыльнең сыйфат һәм фигыль белән уртак яклары. | 1 | Катнаш дәрес | | | С-т фигыльнең заман формалары, сыйфат һәм фигыль белән уртак яклары. | Сыйфат фигыль-ләр кергән 5 мә-каль язарга. | 12.12 | |
| 42 | Хәзерге заман сыйфат фигыль | 1 | Катнаш дәрес | | Сүзлек диктанты 5 мин. | Хәзерге заман сыйфат фигыль-нең *гади һәм тезмә* формалары. Гади формасы фигыль нигезенә – *учы/-үче* кушымчала -ры ялганып, ә тезмә формасы *–а/-ә, –ый/-и гә беткән фигыльләргә + торган яр - дәмче фигыле* белән ясалуы. Хәзерге за- ман сыйфат фигыльнең юклык формасы. | 157нче күнегү, бирем буенча. | 13.12 | |
| 43 | Үткән заман сыйфат фигыль | 1 | Катнаш дәрес | | | Үткән заман сыйфат фигыльнең фигыль нигезенә *–ган/-гән, -кан/-кән* кушымчалары ялганып ясалуы. Үткән заман сыйфат фигыльнең исем урыныда килеп, *килеш, тартым белән төрләнүе, берлек, күплек санда килүе.* Үткән заман сыйфат фигыльнең билгесез үткән заман хикәя фигыль белән аваздашлы . | 160нчы күнегү, бирем буенча. | 17.12 | |
| 44 | Киләчәк заман сыйфат фигыль | 1 | Белемнәрне системага салу дәресе | | Тест куллану. | Киләчәк заман сыйфат фигыль-нең ясалышы:*-ачак/-әчәк, -ячак/-ячәк* кушымчалары белән ясалуы;*-ар/ -әр / -ыр/ - ер/ - р* кушымчалары белән ясалуы; *-асы/ - әсе / - ыйсы / - исе* кушымчалары белән ясалуы; Киләчәк заман сыйфат фигыль-нең киләчәк заман хикәя фигыль белән аваздашлыгы | 166 нчы күнегү, бирем буенча. 2. Шигырьне, яттан диктант итеп әзерләргә | 19.12 | |
| 45 | Хәл фигыль. Хәл фигыльнең төрләре. | 1 | Яңа материал белән таныштыру дәресе | | 166 нче күнегү, яттан диктант. | Төп фигыльдән аңлашылган эш яки хәлгә өстәмә эшне белдереп килгән фигыльнең хәл фигыль дип аталуы. Хәл фигыльнең | 166 нче күнегү, бирем буенча.яттан язу | 20.12 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | *ничек? кайчан? кайчанга чаклы? нишләп? нишләгәч? нишләгәнче?* сорауларына җа- вап бирүе, төрләнмәве. Хәл фигыльнең дүрт төре булуы:<br>-1 төре *–ып / - еп / - п* кушымча - лары ялганып ясала;<br>- 2 төре *– а / -ә / -ый / - и* кушымчалары ялганып ясала, (кабатлаулы була);<br>- 3 төре *– гач / - гәч, - кач / - кәч* кушым - чалары ялганып ясала;<br>- 4 төре *–ганчы / - гәнче / - канчы / - кән -че* кушымчалары ялганып ясала; Дүртен-<br>че төренең юклык формасы булмавы. | | | |
| 46 | Хәл фигыльнең кулланылышы һәм дөрес язылышы. | 1 | Белемнәрне системага салу дәресе | | | Парлы фигыльләрнең дөрес язылышы. Беренче төр хәл фигыльләргә –рак /- рәк кушымчасы ялганганда үзгәрешләр. | 177 нче күнегү, бирем буенча. | 24.12 | |
| 47 | Диктант (контроль) “Сәламәт булырга теләсәң” | 1 | | | “Сәламәт булырга теләсәң” | Грамоталылык һәм белем дәрәҗәсен тикшерү. | Таблица .хәл фигыльтөрләре | 26.12 | |
| 48-49 | Исем фигыль. Исем фигыльнең фигыль һәм исем белән уртак яклары | 2 | Яңа материал белән таныштыру дәресе | | | Исем фигыльнең берьюлы исем һәм фи ыль билгеләренә ия булган, зат-сан белән төрләнми торган сүз төркеме булуы. Аның эш-хәлнең исемен белдерүе, *нәр - сә? нишләү? нишләмәү?* сорау-ларына җавап бирүе. Фигыль билгеләре: барлыкта-юклыкта, юнәлеш формасында була, үзе- нә исемнәр һәм башка сүзләр ияртә алуы Исем билгеләре: *килеш, тартым белән төрләнүе, берлек, күплек санда килүе;* җөмләдә *аергыч, тәмамлык, хәл* булып килүе. | 179 нчы күнегү, бирем буенча.<br>181 нче күнегү, (1-5) бирем буенча. | 27.12<br>14.01 | |
| 50 | Тәрҗемә итү | 1 | Бсү | | Тәрҗемә | Тәрҗемә иткәндә татар һәм рус | Бирем 184 нче | 16.01 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | итү | телләренең җөмлә төзелешенә игътибар итү. | күнегү .исем фигыль турында сөйләргә | | |
| 51 | Исем фигыльнең исемгә әйләнү очраклары | 1 | Катнаш дәрес | | | Исем фигыльнең фигыль билгеләрен югалтса, исемгә әйләнүе. | 185 нче күнегү, бирем буенча. | 17.01 | |
| 52 | Диалог төзү “Гыйлем - сез эш кылган кеше - юлсыз йөргән кеше” | 1 | Бсү | | Диалог. | Татарча аралашу дәрәҗәсен үстерү. | Дәфтәрләргә язып килергә | 21.01 | |
| 53 | Изложение (контроль) | 1 | Бсү | | “Сыерчык” , 67 нче бит | Бирелгән текстның телен һәм стилен саклап язарга өйрәнү | Исем фигыль турында сөйләргә өйрәнеп кил | 23.01 | |
| 54 | Инфинитив | 1 | Яңа материал белән таныштыру дәресе | | | Эш яки хәлне максат яки тиеш булу мәгънәсендә белдереп, сузыкка беткән фигыль нигезенә *–рга / -ргә,* тартыкка беткән нигезгә *–ырга* / - *ергә* / - *арга* / - *әргә* кушымчалары ялганып ясалган фигыльнең инфинитив дип аталуы. *Нишләргә? нишлә- мәскә?* сорауларына җавап булу. Инфинитивның кулланылышы: икенче фигыльгә ияреп килүе; *кирәк, тиеш, мөмкин ярый,* кебек хәбәрлек сүзләр белән килүе; мөстәкыйль кулланылуы. Инфинитивның архаиклашкан һәм хәзерге телдә сирәк очрый торган төре: - *мак* / - *мәк* кушымчалары ялганып ясалуы. | 194 нче күнегү, бирем буенча. | 24.01 | |
| 55 | Диктант.”Хезмәт” | 1 | | | “Хезмәт” | Грамоталылык һәм белем дәрәҗәсен тикшерү. | Инфинитив турында сөйләргә өйрәнеп килергә | 27.01 | |
| 56 | Ярдәмче фигыльләр | 1 | Яңа материал белән таныштыру дәресе | | | Ярдәмче фигыльләр: *иде, икән, ит.* Аларның мөстәкыйль мәгънә белдермәве, аерым кулланылмавы. | 200 нче күнегү, бирем буенча. | 30.01 | |
| 57 | Рәсем буенча хикәя язу. МТК | 1 | Бсү | | Хикәя | “Бөгелмә ягы- туган як” темасына хикәя язу. Туган якның матурлыгын, байлыгын тасфирлау. | Дәфтәрләргә язып килергә | 31.01 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 58 | Мөстәкыйль фигыльләрнең ярдәмче фигыль ролендә йөрүе. | 1 | Катнаш дәрес | | | Кайбер мөстәкыйль фигыль - ләрнең (*кит, кил, чык, бар, йөр, җибәр, бет, ал, бир, куй, кал, тор, ят, утыр, ташла, сал, күр, кара, яз, бул*) җөмлә эчендә ярдәмче фигыль ролендә йөрүе, аларның төп фигыльгә төрле мәгънә төсмерләре өстәве. | 205 нче күнегү, бирем буенча. | 04.02 | |
| 59 | Изложение | 1 | Бсү | | “Сыерчык килгән”, 209 нчы бит. | Бирелгән текстның телен һәм стилен саклап язарга өйрәнү. | Дәфтәрләргә язып килергә | 06.02 | |
| 60 | Фигыль ясагыч кушымчалар | 1 | Катнаш дәрес | | | Ясалышлары ягыннан фигыль-ләрнең тамыр һәм ясалма булу - лары. Фигыль ясагыч кушымча-лар. Аларның төрле сүз төркем-нәреннән фигыль ясавы. | 209 нчы күнегү, бирем буенча. | 07.02 | |
| 61 | Фигыльләрнең җөмләдә кулланылышы | 1 | Белемнәрне системага салу дәресе | | Тест 7 мин | Фигыльләрнең җөмләдә төрле җөмлә кисәкләре булын йөрүләре. | 213 нче күнегү, бирем буенча. | 11.02 | |
| 62 | Хикәя язу. МТК. “Безнең елга” темасы буенча. | 1 | Бсү | | | | Дәфтәрләргә язып килергә | 13.02 | |
| 63-65 | Фигыльләрне гомумиләштереп кабатлау | 3 | Белемнәрне йомгаклау һәм системага салу дәресе | | Тест 30 мин. | Бүлек буенча өйрәнгәннәрне кабатлау. Фигыльләргә морфо-логик һәм морфологик- синтак-сик анализ ясарга өйрәнү.<br>Бсү. Акт язу. | 216, 218 нче күнегүләр, бирем буенча. | 14.02<br>18.02<br>20.02 | |
| 66 | Сочинение язуга әзерлек | 1 | Бсү | | | Укучылар белән укылган әсәр-ләрне искә төшерү, анализлау. | Материал тупларга | 21.02 | |
| 67 | Сочинение “Мине уйландырган әсәр”. | 1 | Бсү | | Сочинение №3 | | Дәфтәрләргә язып килергә | 25.02 | |
| | | | **А В А З   И Я Р Т Е М Н Ә Р Е** | | | | | | |
| 68 | Аваз ияртемнәре | 1 | Яңа материал белән таныштыру дәресе | | | Кеше һәм башка җан ияләре чыгарган авазларга , шулай ук төрле предметлар һәм табигать күренешләренең тавышларына охшатып ясалган сүзләрне аваз ияртемнәре дип аталулары. Аваз ияртемнәренә кешенең физиологик хәлен, күреп яки тоеп | 211 нче күнегү, бирем буенча. | 27.02 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | сиземләнә торган күренешләрне белдерә торган сүзләрнең дә керүе. Аваз ияртемнәренең мөстәкыйль сүз төркемнәренә керүе, аңа морфологик анализ ясый белү. | | | |
| 69 | Белдерү | 1 | Бсү | | Белдерү | | Белдерү-реклама язып кил | 28.02 | |
| 70 | Аваз ияртемнәре | 1 | Катнаш дәрес | | | Аваз ияртемнәренең төзелеш - ләре һәм язылышлары буенча - *ялгызак*; берүк сүзне кабатлап ясалган - *парлы*; икенче сүзе фонетик яктан охшаш булган - *парлы*; берничә өлештән торган - *катлаулы* булуы. Ялгызак авыз ияртемнәренең аерым, парлы авыз ияртемнәренең сызыкча аша, катлаулы авыз ияртемнә -ренең сызыкча аша һәм күпнок- талар аша язылуы. | 220нче күнегү, бирем буенча. | 04.03 | |
| 71 | Авыз ияртемнәренең сүзләр ясауга нигез булып торулары | 1 | Катнаш дәрес | | Тестлар куллану | Авыз ияртемнәренең исем һәм фигыльләр ясауга ясауга нигез булып торулары. Аваз ияртем - нәрнә ит һәм кил ярдәмче фи - гыльләре өстәлеп, тезмә фигыль - ләр ясалу. | 227 нче күнегү, бирем буенча. | 06.03 | |
| 72 | Авыз ияртемнәренең җөмләдә кулланылышы. Тәрҗемә итү күнегүләре. | 1 | Катнаш дәрес | | | Авыз ияртемнәренең, җөмләдә башка сүзләр белән бәйләнешкә кереп, рәвеш хәле, хәбәр булып килүләре, кайбер очракта аергыч була алулары. | Сочинениегә әзерләнергә. | 07.03 | |
| 73 | Сочинение. МТК “Данлыклы якташларым”” | 1 | Бсү | | Сочинение –фикер йөртү | Катлаулы план нигезендә язу | Дәфтәрләргә язып килергә | 11.03 | |
| | | | **Х Ә Б Ә Р Л Е К   С Ү З Л Ә Р** | | | | | | |
| 74 | Хәбәрлек сүзләр турында төшенчә | 1 | Яңа материал белән таныштыру дәресе | | | Раслау я кире кагу мәгънәсен белдерә торган *сүзләрнең хәбәрлек сүзләр* дип аталуы. | 231 нче күнегү, бирем буенча. | 13.03 | |
| 75 | Хәбәрлек сүзләр | 1 | Катнаш дәрес | | | Татар телендә хәбәрлек сүзләр - | Хәбәрлек сүзләр | 14.03 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | нең тоткан урыны. Аларның күбесенчә җөмләне тәмамлап хәбәр булып килүләре. Җөмлә - нең башка урынында килсә, хәбәрлек сүзләрнең башка сүз төркемнәре функциясен үтәве, җөмләнең төрле кисәге булып килүе. | кергән 10 җөмлә уйлап яз | | |
| 76 | Хәбәрлек сүзләргә морфологик анализ | | Белемнәрне системага салу дәресе | | | Хәбәрлек сүзләргә морфологик анализ ясау күнегүләре | Инша “Безнең елга” | 18.03 | |
| 77 | Диктант .”Батырлар даны мәңгелек” | 1 | | | Диктант .”Батырлар даны мәңгелек” | Грамоталылык  һәм белем дәрәҗәсен тикшерү. | | 20.03 | |
| 78 | Язма эшләрне бергәләп тикшерү | 1 | Белемнәрне системага салу дәресе | | | Игътибарлылык дәрәҗәсен тикшерү. | Бирелгән сүзләр белән җөмләләр төзеп яз | 21.03 | |
| | | | **Б Ә Й Л Е К** | | | | | | |
| 79 | Бәйлек | 1 | Яңа материал белән таныштыру дәресе | | | Бәйлек – бәйләгеч сүз төркемнәренең берсе. Аның җөмләдә ияртүче кисәкне ияртүче кисәккә һәм иярченле кушма җөмлә өлешләрен бер-берсенә бәйләве. | 236 (2) нче күнегү, җөмләләр җөзергә. | 01.04 | |
| 80-81 | Бәйлекләрнең төркемчәләре | 2 | Катнаш дәрес | | | Үзләреннән алда килгән сүзнең нинди килештә килүен таләп итүеннән чыгып, бәйлекләрнең өч төркемчәгә бүленүе:<br>- баш килешне таләп итүче бәйлекләр (*белән, өчен, кебек, шикелле, төсле, кадәр, чаклы, хәтле, тикле*);<br>- юнәлеш килешен таләп итүче бәйлек- ләр: (*таба, күрә, каршы, кадәр, чаклы, хәтле, тикле*);<br>- чыгыш килешен аләп итүче бәйлекләр: (*башка, бирле, соң, элек*).<br>Бәйлекләрнең ияртүче сүзне ияртүче сүзгә бәйләгәндә төрле | 240 нчы күнегү, бирем буенча | 03.04<br>04.04 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | мәгънә мөнәсәбәтләрен (бергәлек, корал, вакыт һ.б. мәгънәләр) белдерүе. | | | |
| 82 | Сочинение “Нинди һөнәр сайларга” темасы буенча | 1 | Бсү | | Сочинение №5 | | Дәфтәрләргә язып килергә | 08.04 | |
| 83 | Бәйлек сүзләр | 1 | Яңа материал белән таныштыру дәресе | | | Җөмләдә *ас, өс, ян, як, эч, тыш, буй, чит, арт, ара, тирә, урта, төп* кебек урын-ара төшен - чәләрен белдергән исемнәрнең бәйлек сүз булып килүләре. Бу вакытта аларның икенче бер сүзгә иярүләре, тартымлы юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешендә булулары. | 245 нче күнегү, бирем буенча | 10.04 | |
| 84 | Бәйлекләргә морфологик анализ ясау | 1 | Белемнәрне системага салу дәресе | | | Бәйлекләргә морфологик анализ ясау | 246 нчы күнегү, бирем буенча, эшләп бетерергә | 11.04 | |
| 85 | Изложение | 1 | Бсү | | Изложение №5 “Конфет кайда үсә”, 212 нче бит | Эчтәлекне киңәйтеп язу | Дәфтәрләргә язып килергә | 15.04 | |
| | **Т Е Р К Ә Г Е Ч** | | | | | | | | |
| 86 | Теркәгеч | 11 | Яңа материал белән таныштыру дәресе | | | Теркәгечнең җөмлә кисәкләрен һәм кушма җөмләдә гади җөмләләрне үзара бәйләү өчен кулланыла торган ярдәмлек сүз төркеме булуы. | 248 нче күнегү, бирем буенча | 17.04 | |
| 87 | Теркәгечләрнең төркемчәләре. Тезүче теркәгечләр. | 1 | Катнаш дәрес | | | Теркәгечләрнең *тезүче һәм ияртүче* төркемнәргә бүленүе. Тезүче теркәгечләрнең җөмлә - нең тиңдәш кисәкләрен һәм тезмә кушма җөмлә өлешләрен үзара бәйләү -ләре; *җыю, каршы кую, бүлү* кебек мәгънә бәйләнешләрен белдерүләре. | 250 нче күнегү, бирем буенча | 18.04 | |
| 88 | Теркәгечләрнең төркемчәләре. Ияртүче теркәгечләр | 1 | Яңа материал белән таныштыру | | | Теркәгечләрнең *тезүче һәм ияртүче* төркемнәргә бүленүе. Ияртүче теркәгечләрнең иярчен | 252 нче күнегү, язып бетерергә. | 22.04 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | дәресе | | | кисәкне ияртүче кисәккә һәм иярченле кушма җөмләдә ияртү юлы белән өлешләрне үзара бәйләве; сәбәп, шарт, кире шарт, чагыштыру һәм ачыклау кебек мәгъгә бәйләнешләрен белдерү. | | | |
| 89 | Теркәгеч сүзләр | 1 | Катнаш дәрес | | Тест 7 мин. | Теркәгеч сүзләрнең җөмләләрне һәм җөмлә кисәкләрен бер-берсенә бәйләү өчен хезмәт итүе. Аларның ялгызак булганда күрсәтү алмашлыгы белән, парлы булганда сорау һәм күрсәтү алмашлыклары белән белдерелүләре. | Әдәби әсәрдән теркәгеч сүзләр белән 5 җөмлә язып алырга. | 24.05 | |
| 90 | Теркәгечләрнең дөрес язылышы | 1 | Белемнәрне системага салу дәресе | | | Теркәгечләрнең һәрвакыт аерым язылулары. Теркәгеч (*да. дә, та, тә*) бе -лән кисәкчәләрне *(-да / -дә / - та / - та / - тә)* аеру билгеләрен белү.<br>1.Урын –вакыт кушымчасына басым төшә, теркәгеч белән кисәкчәгә бервакытта да басым төшми.<br>2.Урын- вакыт кушымчасын алган сүзнең кемдә? нәрсәдә? кайда? кайчан? кебек сорауларның берсенә җавап бирүе.<br>3. Теркәгеч урынына һәм сүзен куеп карап булу. | 256 нчы күнегү, бирем буенча | 25.04 | |
| 91 | Сочинение “Муса Җәлил һәйкәле янында уйланулар” | 1 | Бсү | | Сочинение №6 | Сөйләм төрләрен (сыйфатлау, хикәяләү, фикер йөртү) кулланып, фикерне эзлекле язу. | Дәфтәрләргә язып килергә | 29.04 | |
| | **К И С Ә К Ч Л Ә Р** | | | | | | | | |
| 92 | Кисәкчә | 1 | Яңа материал белән таныштыру дәресе | | | Аерым сүзләрнең яки җөмләләр-нең мәгънәләренә өстәмә төсмер бирә торган сүз төркеменең кисәкчә дип аталуы. | 259 нчы күнегү, бирем буенча | 01.05 | |
| 93 | Кисәкчә төркемчәләре | 1 | Катнаш дәрес | | | Аерым сүзләрнең яки җөмләләр-нең мәгънәләренә нинди өстәмә төсмер бирүенә карап, кисәкчә-ләрне сигез төркемчәгә (көчәйт - | 258 нче күнегү, бирем буенча | 02.05 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | кечләр, чикләүчеләр, сорау бел - дерүчеләр, якынлык-ераклык яки тизлекне белдерүчеләр, рас- лау- ныгытучылар, билгесезлек, икеләнүне белдерүчеләр, үтенү һәм теләкне белдерүчеләр, инкарь итүне һәм юклыкны белдерүчеләр) бүленүе. | | | |
| 94-95 | Кисәкчәләрнең дөрес язылышы | 2 | Белемнәрне системага салу дәресе | | | Кисәкчәләрнең дөрес язылы -шын үзләштерү. Көчәйткеч кисәкчәләрдән: сүзнең беренче иҗегенә артыклык дәрәҗәсе ясый торган кисәкчәләр сызык -ча аша языла; сүзнең беренче иҗеге белән уртаклыгы булма -ган кисәкчәләр аерым языла. *Һич* кисәкчәсе юклык алмашл -ыгы ясаганда кушылып языла, ә башка очракта аерым языла. Сүз ахырында килә торган *–мы, -ме, -мыни, -мени, -дыр, -дер, -тыр, -тер, - чы, -че, -сана, -сәнә* кисәкчәләре кушылып языла. Сүз яки җөмлә ахырын -да килгәндә *да, дә, та, тә, гына, генә, ук, үк, ла, лә, лабаса, ләба -са, бит, и, түгел* китсәкчәләре аерым языла. Сүзләрнең яки җөмләнең алдында да, ахырын- да да килә ала торган *әле, әллә, инде, хәтта* кисәкчәләре һәрва- кытта да аерым языла. Кисәкчә-<br>ләргә морфологик анализ ясый белү. | 264 нче күнегү, бирем буенча | 06.05<br>08.05 | |
| 96 | Сочинение (контроль) “Әниемнең җылы кочагы...”. | 1 | Бсү | | Сочинение №7 | Сөйләм төрләрен (сыйфатлау, хикәяләү, фикер йөртү) кулланып, фикерне эзлекле язу. | 265 нче күнегү | 09.05 | |
| | **Ы М Л Ы К Л А Р** | | | | | | | | |
| 97 | Ымлыклар | 1 | Яңа материал белән таныштыру | | | Кешенең эчке кичерешләрен, хис- тойгыларын, теләк-ихтыяр- ларын кыска рәвеш -тә белдерә торган | 266 нчы күнегү, эшләп бетерергә. | 13.05 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | дәресе | | | сүзләрнең ымлыклар дип аталуы. Ымлыкларның төрлән- мәве. Ымлыкларның кешенең эчке кичерешләрен (якын күрү, кызгану, шелтәләү, шатлану, күңел күтәренкелеге, борчылу, үкенү, кайгыру, икеләнү, гаҗәп-ләнү, раслау, сызлану, ис китү, аптырау, тыю, нәфрәт, җирәнү һ.б.) белдерүе. | | | |
| 98 | Ымлыклар янында тыныш билгеләре | 1 | Катнаш дәрес | | | Ымлыкларның җөмләнең башка кисәкләреннән күбрәк өтер белән аерылулары. Көчле тойгы белән әйтелгәндә ымлыктан соң өндәү билгесе куелу. Парлы ымлыкларның сызыкча аша язылуы. Ачык ишетелмәгән авазларның язылуда күрсәтел-мәве. Ымлыкларга морфологик анализ ясау. | Әдәби әсәрдән ымлыклар белән 5 җөмлә язып алырга. | 15.05 | |
| 99 | Уку елы дәвамында үткәннәрне кабатлау | 1 | Белемнәрне йомгаклау һәм системага салу дәресе | | | Уку елы дәвамында үткәннәрне кабатлау. | 276, 278 нче күнегүләр, бирем буенча | 16.05 | |
| 100 | Контроль диктант. “Җәй” | 1 | | | “Җәй” | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү | Җәйге ял турында диалог төзеп кил | 20.05 | |
| 101 | Хаталар өстендә эш | 1 | | | | | “Татар теле- туган телем” темасына диалог төзеп килергә | 22.05 | |
| 102 - 103 | Кабатлау дәресе | 2 | | | | | | 23.05 27.05 | |
| 104 - 105 | Йомгаклау дәресләре. | **2** | | | | 7 сыйныф татар теле курсына йомгак ясау. | | 29.05 30.05 | |

**Татар теленнән язма эшләр һәм аларны бәяләү критериясе**

**Сүзлек диктанты күләме**

**Бәяләү**

| Мәктәп тибы<br>Билге | Татар һәм рус мәктәпләрендә укучы татар балалары | Рус телле балалар |
|---|---|---|
| “5” | Хатасыз | Хатасыз,пөхтә |
| “4” | 1-2 хата | 1-2 хата |
| “3” | 3-4 хата | 3-5 хата,4-5 төзәтү |
| “2” | 5 һәм күбрәк хата | 6 һәм күбрәк хата |

**Контроль диктант күләме**

| Мәктәп тибы<br>Сыйныф | Рус мәктәбендә татар балалары | | Рус телле балалар | |
|---|---|---|---|---|
| | Ел башы | Ахыры | Ел башы | Ахыры |
| I | - | - | - | - |
| II | | | 25 | 30 |
| III | | | 30 | 35 |
| IV | | | 35 | 40 |
| V | 50 | 50-60 | 35-40 | 40-45 |
| VI | 55-65 | 60-70 | 45-50 | 50-55 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| VII | 65-80 | 85-100 | 55-60 | 60-65 |
| VIII | 85-100 | 95-110 | 65-75 | 75-80 |
| IX | 105-120 | 115-125 | 80-90 | 90-100 |
| X | 120-130 | 125-135 | 95-105 | 105-115 |
| XI | 130-140 | 135-140 | 110-120 | 115-125 |

**Бәяләү**

| Мәктәп тибы<br><br>Билге | Рус мәктәбендә татар балалары | Рус телле балалар |
|---|---|---|
| “5” | 0/0,0/2,1/0 | 0/0,1/0, 0/1 |
| “4” | 2-3/3-2 | 2/2, 3/2, 2/3 |
| “3” | 4/4, 3/6 | 4/4, 3/6 |
| “2” | 6/5, 5/8 | 6/5,5/8 |
| “1” | | |

**Изложение**

**Текстның күләме**

| Мәктәп тибы<br><br>Сыйныф | Рус мәктәбендә татар балалары | | Рус телле балалар | |
|---|---|---|---|---|
| | Ел башы | Ахыры | Ел башы | Ахыры |
| V | 70-110 | 110-140 | 55-65 | 65-75 |
| VI | 140-160 | 160-190 | 70-80 | 85-95 |
| VII | 190-230 | 230-270 | 90-95 | 100-100 |
| VIII | 270-310 | 310-350 | 110-120 | 120-130 |
| IX | 350-370 | 370-390 | 130-140 | 140-150 |
| X | 390-410 | 410-430 | 150-160 | 165-175 |
| XI | 430-450 | 450-470 | 175-180 | 190-210 |

**Бәяләү**

| Мәктәп тибы Билге | Рус мәктәбе | Рус телле балалар |
| --- | --- | --- |
| “5” | Эчтәлек темага туры килә, фактик хаталары юк, теле бай, стиль бердәмлеге сакланган; 1 орфографик яисә 2 пунктуацион (грамматик) хата. | Эзлекле язылган һәм эчтәлек тулысынча ачылган; 1 орфографик, 1 пунктуацион яки 2 грамматик хата. |
| “4” | Эчтәлек нигездә темага туры килә; зур булмаган ялгышлыклар күзәтелә; 1-2 фактик хата; 2 орфографик, 3 пунктуацион ( грамматик) яисә бер-ике сөйләм хатасы. | Тема эзлекле язылган, ләкин 2-3 эчтәлек ялгышы, 2-3 орфографик, 2-3 пунктуацион. хата |
| “3” | Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлыклар, фактик төгәлсезлекләр; эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаган;теле ярлы; орфографик, 4 пунктуацион (грамматик) яисә 3-4 сөйләм хата. | Тема өлешчә эзлекле язылган; эчтәлек тулысынча ачылмаган; 4-5 орфографик, 4-5 пунктуацион хата. |
| “2” | Язма темага туры килми; Фактик төгәлсезлекләр күп; теле ярлы; текст кыска; сүзләр дөрес кулланылмаган; стиль бердәмлеге сакланмаган; 5 орфографик, 8 пунктуацион (грамматик), яисә 4-6 сөйләм хатасы. | Тема эзлекле язылмаган һәм эчтәлеге ачылмаган, 6 дан артык орфографик, 6 дан артык пунктуацион һәм грамматик хата. |

**Сочинениене бәяләү**

| Мәктәп тибы Билге | Рус мәктәбе | Рус телле балалар |
|---|---|---|
| “5” | Эчтәлек темага туры килә, фактик хаталары юк, теле бай, стиль бердәмлеге сакланган; 1 орфографик яисә 2 пунктуацион (грамматик) хата. | Эзлекле язылган һәм эчтәлек тулысынча ачылган; 1 орфографик, 1 пунктуацион яки 2 грамматик хата. |
| “4” | Эчтәлек нигездә темага туры килә; зур булмаган ялгышлыклар күзәтелә; 1-2 фактик хата; 2 орфографик, 3 пунктуацион ( грамматик) яисә бер-ике сөйләм хатасы. | Тема эзлекле язылган, ләкин 2-3 эчтәлек ялгышы, 2-3 орфографик, 2-3 пунктуацион хата. |
| “3” | Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлыклар, фактик төгәлсезлекләр; эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаган;теле ярлы; орфографик, 4 пунктуацион (грамматик) яисә 3-4 сөйләм хата. | Тема өлешчә эзлекле язылган; эчтәлек тулысыңча ачылмаган; 4-5 орфографик, 4-5 пунктуацион хата. |
| “2” | Язма темага туры килми; Фактик төгәлсезлекләр күп; теле ярлы; текст кыска; сүзләр дөрес кулланылмаган; стиль бердәмлеге сакланмаган; 5 орфографик, 8 пунктуацион (грамматик), яисә 4-6 сөйләм хатасы. | Тема эзлекле язылмаган һәм эчтәлеге ачылмаган, 6 дан артык орфографик, 6 дан артык пунктуацион һәм грамматик хата. |

**Укыту – методик комплекты**

“Рус мәктәпләрендәукучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары”на (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Р.Ф.Җамалетдинова. Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2010)

Рус мәктәпләрендәге татар балаларына татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты.(Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М.,Хаков В.Х., Измайлова Г.Г., Хәмидуллина Э.Х.Казан, 2005)

7 нче сыйныфта татар теле дәреслеге. (Р.Ә. Асылгәрәева, М.З. Зиннәтова. . Казан, “Мәгариф” , 2005 ,2010.)

Тата теле морфологиясе. /Ф.М. Хисамова. - Казан, “Мәгариф” , 2005.

Хәзерге татар әдәби теле. / Ф.С. Сафиуллина, М.З.Зәкиев.- Казан, “Мәгариф” , 1994.

Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. / Ф.С.Вәлиева, Г.Ф. Саттаров. – Казан: “Раннур”, 2000.

7 нче сыйныф.

Рус мәктәпләренең

татар төркемнәре өчен

**7 “а” сыйныфы укучылары өчен 1 яртыеллыкка татар теленнән диктант текстлары (татар төркеме).**

**Сайланма диктант.**

**Әбекәй**

Әбекәй! Нинди матур син! Җыйнак гәүдәңә, ягымлы кара күзләреңә, җыерчыклар сарган битеңә, көмеш төс кергән чәчләреңә,вак-вак атлап йөрешеңә, сокланып карыйм мин. Һәрвакыт өстеңдә үзең теккән килешле күлмәк, башыңда ак яулык, аякларыңда йон оекбаш һәм җыйнак кәвеш булыр.

Син үстергән гөлләргә дә сокланмаган кеше юктыр. Аларның нинди генә төре юк синдә!

Әбекәй! Син- тыйнак та, сөйкемле дә. Син-эшчән дә, түземле дә , иманлы да. Син- өебезнең яме, ашыбызның тәме. Гаилә учагын сүндермичә син дөрләтеп торасың. (76 сүз)

**Бирем.1.Беренче абзацтагы җөмләләрдән тартым белән төрләнгән исемнәрне табып, асларына сызыгыз.**

**2. Текстан рәвешләрне табыгыз.**

**Контроль изложение**

**Куян рәхмәте**

Малай балыкка китте. Җайлырак, тынычрак урынны сайлап йөри торгач, ярдан читтәрәк ниндидер тавыш колакка чалынды. Барып караса, куак артында яраланган куян ята. Кемдер аңа аткан, тик таба алмаган. Куянның бәхете бар икән. Качып торырга акылы җиткән. Ана куян булырга тиеш, чөнки бәләкәйрәк, ә зуррагы аны саклый.

Малай озынколак янына килде. Куян калтыранды, әмма куркуын җиңде. Ата куян якында гына сикергәләп торды. Алар кем белән эш итүләрен аңлыйлар иде шикелле.

Малай яралы куянны кулына алды, башыннан сыйпады, кочаклап сөйде. Куян бөтенесенә дә риза булып, тыпырчынмыйча гына ярдәм көтте. Җәрәхәт аякларында икән. Кемдер аны казанга салырга ниятләсә дә, ул тереләчәк.

Малай куянны өенә алып кайтты. Ул аны дәвалады һәм кире таныш куаклар арасына китереп куйды.

Куянның үзен терелткән дустыннан аерыласы килмәде. Ул, байтак вакыт аңа карап, иренен селкеткәләде. Куян нәрсәдер әйтергә теләде. Үзенчә рәхмәт белдергәндер.

Шулай да хушлашырга барыбер кирәк иде. Куянның күндәмлегеннән артык файдаланмас өчен, малай кулын шапылдатып куйды. Озынколак сискәнеп китте, тик аннары, тиз тынычланып, тагын бер урында сикергәләп торды. Шуннан соң гына, каты ыргылып, куаклыкка кереп югалды.(169 сүз)

(Әхсән Баяновтан)

**Диктант**

**Чын бәхет**

Көн дәверендә без әллә ничә мәртәбә бәхет дигән сүзне кулланабыз. Берәр сөенечле хәбәр ишетсәк, сөенәбез, куанабыз, үзебезне дөньядагы иң бәхетле кеше итеп саный башлыйбыз. Тик без чын бәхетне, бәхетле булуның нәрсәдә икәнен аңлап бетермибез.Ниләр кирәк бәхетле булыр өчен? Минемчә, бәхетле кеше ул-әти-әнисе янәшәсендә, дус, тату гаиләдә үскән кеше. Әти-әниең, абый-апаларың һәм дус-туганнарың булса, алардан да зуррак хәзинә юктыр.Алар янәшәңдә булса, димәк, сине яратучылар, яклаучылар, сиңа ярдәм итүчеләр бар. (82 сүз)

(А.Латыповадан)

**Бирем. Төзергә, өйгәннәр, утырту, юынды, кулланыла, куаныштылар фигыльләренең башалангыч формасын аерып языгыз.**

**Диктант**

**Алмаз бабай бакчасы**

Алмаз **бабайның** бакчасы Хәкимне генә **түгел**, башка балаларны да үзенә тарата. **Андый** бакча авылда бер генә шул.

Хәкимнең бу алма бакчасына кергәне бар.Ул үзенең матурлыгы  һәм **төрле җиләк-җимешләре** белән дан тота. Бабай үзе дә гел шунда кайнаша:Җир йомшарта, чүп утый,яралы, авыру агачларны дәвалый. Ә җәйләрен анда чия, кура җиләге, тагын башка җимешләр берсе артыннан берсе пешеп тора. Көз көне хуш исле тәмледән- тәмле, төрледән –төрле алмалар, алланып пешеп, агач ботакларында бәйрәм утлары кебек эленеп **торалар**.. Өз дә аша, өз дә аша.....

**Биремнәр**

1. **Текстан фигыльләрне табып асларына сызарга.**
2. **Билгеләнгән сүзләрнең басымнарын куярга.**

**Сәламәт булырга теләсәң.**

**Контроль диктант.**

Икенче ел инде иртән тору белән трусиктан гына, яланаяк ындыр артына кадәр йөгереп кайтам. Быел җәй велосипед спидометры белән үлчәп караган идем,төгәл алты йөз метр чыкты.
Әнә шул араны йөгергәндә, миңа һәрвакыт күршеләрнең Актабаны иярә. Әллә аның да гадәтенә керде инде, капкадан чыкканны көтеп кенә тора. Мин йөгерәм, Актабан чаба, кайвакыт өрә-өрә авылның башка этләре дә кушыла, Каршыга җилләр исә, суык көннәрдә тын куырыла, бураннарда чәчкә кар кереп адаша, ә без узыша-узыша йөгерәбез.
Йөгереп кайту белән өйгә кермим. Ашыкмыйча гына физик күнегүләр ясыйм. Миннән пар бөркелә, яланаякларым баскан урында, кар эреп, чокыр ясала. Күнегүләр тәмамлангач, кар белән уынасы яки коедан су тартып коенасы гына кала. Аннан шадра сөлге белән тәнең бурлаттай кызарганчы сөртәсең.

**(Нур Әхмәдиевтән)**

**Бирем. 1.*Күршеләрнең, куырыла* сүзләрен төзелеше ягыннан тикшерегез.**

***Быел* сүзенә морфологик анализ ясагыз.**

**7 “а” сыйныфы укучылары өчен II яртыеллыкка татар теленнән  диктант текстлары (татар төркеме).**

**Диктант.**

**Хезмәт.**

Хезмәт- күп мәгънәле сүз. “Хезмәт”сүзе горур һәм матур яңгырый. Хезмәттән башка тормыш, дөньяда яшәүнең мәгънәсе юк. Халык элек-электән үк хезмәт турында күп мәкаль иҗат иткән. Эшләп аша, күп яшә. Эшләмичә ашап булмый, ашамасың яшәп булмый.

Без әле эшләмибез. Ләкин безнең эшебез, хезмәтебез-уку. Килер бер вакыт, һәм без һәрберебез дә эшебездәге уңышларыбыз белән илне куандырырбыз. Моңа без чиксез ышанабыз, чөнки безнең алда ачылмаган серләр, үтелмәгән юллар ята. (68 сүз)

(Г.Әдһәмовтан)

**Бирем.**

**Текстан фигыльләрне табып, төркемчәләрен күрсәтергә.**

**Диктант**

**Батырлар даны мәңгелек**

Туган ил! Күңелләргә гаҗәеп якын, изге ул!

Илебез тормышында төрле вакыйгалар булып узган. Кайгы- хәсрәт тә читләтеп үтмәгән. Бөек Ватан сугышы башлангач, ир-егетләрен фронтка озаткан. Егетләр, данлы юллар үтеп, илгә җиңү яулап, туган якларына кайтканнар. Ә күбесе, туган иле, туган җире өчен батырларча һәлак булган. Юк батырлар үлмиләр. Батырларның даны мәңгелек! Алар хөрмәтенә авыл һәм шәһәрләр уртасында һәйкәлләр калкып чыкты. Ә алар тирәсендә ямь-яшел чыршылар үсә.Әйтерсең яшел шинельле батырлар торып басканнар. (74 сүз)

(И.Галимовтан)

**Бирем.**

**Кайтканнар сүзенә морфологик анализ ясарга.**

**Контроль диктант**

**Җәй**

Җәй! Исеменнән үк ниндидер бер рәхәтлек, яктылык, җылылык бөркелә аның. Җәй диюгә үк, хәтердә салават күперле җылы яңгырлар, чәчәкле болыннар, кайнар комлы елгалар яңара. Колакларга кошлар сайравы ишетелгәндшй була. Телләрдә җиләк, бал тәмнәре сизелә. Җәй иң күңелле, иң рәхәт фасыл дисәк, каршы килүче табылмас, шәт.

Җәй озын-озак яллар, каникуллар да әле ул. Хыялларның да канат җәйгән, илһамның да күңел кылларын чирткән вакытыю Шуңадыр инде, җәйне һәркем ел буе сагынып көтә.

(71 сүз)

(Й.Шәрәповадан)

**Бирем**

1. **Фигыльләрнең тамырыннан инфинитив ясап язарга:күр, сөйлә, чакыр, көт, кит, йөр.**
2. **Ишетелгәндәй сүзенең төзелешен тикшерергә.**